КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 25 декабрь г.Казань № 1184

2020 елда каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча юридик затларга - «Экология» илкүләм проектының «Каты коммуналь калдыклар белән эш итүнең комплекслы системасы» федераль проекты максатларына, күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итүче төбәк операторларына каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча өзлексез эшне тәэмин итүгә бәйле чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү кагыйдәләрен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының «Экология» илкүләм проектының «Каты коммуналь калдыклар белән эш итүнең комплекслы системасы» федераль проекты максатларына, күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итүче каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча төбәк операторларның өзлексез эшен тәэмин итүгә бәйле чараларны гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан башка бюджетара трансфертлар бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 9 апрелендәге 473 номерлы карары, Татарстан Республикасы бюджет кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән 2020 елда каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча юридик затларга - «Экология» илкүләм проектының «Каты коммуналь калдыклар белән эш итүнең комплекслы системасы» федераль проекты максатларына, күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итүче төбәк операторларына каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча өзлексез эшне тәэмин итүгә бәйле

чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү кагыйдәләрен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин